ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

«Татарстан Республикасы Сайлау кодексына үзгәрешләр кертү турында» 70-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутаты А.Г. Хәбибуллин тарафыннан кертелгән «Татарстан Республикасы Сайлау кодексына үзгәрешләр кертү турында» 70-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проектын беренче укылышта кабул итәргә.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2025 елның 18 апреле
№ 264-VII ДС

Проект
Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы депутаты
А.Г. Хәбибуллин
тарафыннан кертелә

**Татарстан Республикасы Сайлау кодексына үзгәрешләр кертү турында**

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1 статья**

Татарстан Республикасы Сайлау кодексына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2007, № 5, № 12 (I өлеш); 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 8 (I өлеш), № 12 (I өлеш); 2012, № 6 (I өлеш); 2013, № 10; 2014, № 5; 2015, № 5; 2016, № 4, № 6 (I өлеш); Татарстан Республикасы законнар җыелмасы, 2017, № 27 (I өлеш), № 52 (I өлеш), № 55 (I өлеш); 2018, № 44 (I өлеш), № 83 (I өлеш); 2019, № 2 (I өлеш), № 28 (I өлеш); 2020, № 4 (I өлеш); 2021, № 1 (I өлеш), № 29 (I өлеш), № 93 (I өлеш); 2022, № 77 (I өлеш); 2023, № 11 (I өлеш), № 27 (I өлеш), № 48 (I өлеш), № 73 (I өлеш), № 81 (I өлеш); 2024, № 18 (I өлеш), № 44 (I өлеш), № 79 (I өлеш) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяга түбәндәге эчтәлекле 3 өлеш өстәргә:
«3. Чит ил гражданнары, әлеге Кодексның 4 статьясындагы 11 өлешендә күрсәтелгән очрактан тыш, гражданлыгы булмаган затлар, чит ил оешмалары, халыкара оешмалар һәм халыкара иҗтимагый хәрәкәтләр, чит ил агентлары кандидатларны, кандидатлар исемлекләрен күрсәтүгә, теркәлгән кандидатларны сайлауга, сайлауларда билгеле бер нәтиҗәгә ирешүгә ярдәм йә комачау итә торган эшчәнлекне гамәлгә ашырырга, шулай ук башка рәвешләрдә сайлау кампанияләрендә катнашырга хокуксыз.»;

2) 4 статьяның 2 өлешендәге беренче җөмләсен түбәндәге редакциядә бәян итәргә: «Татарстан Республикасы Рәисе вазыйфасына кандидат итеп Россия Федерациясендә даими яшәүче, пассив сайлау хокукына ия булган, тавыш бирү көненә 30 яшькә җиткән Россия Федерациясе гражданы күрсәтелергә мөмкин.»;

3) 10 статьяның $13^1$ өлешендәге беренче абзацында «инвалидларның федераль реестры белешмәләре» сүзләрен «Социаль өлкәдә бердәм үзәкләштерелгән цифрлы платформа» дәүләт мәгълүмат системасындагы белешмәләр» сүзләренә алмаштырырга;

4) 16 статьяның $6^{1-1}$ өлешендә «Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе» сүзләрен «территориясендә сак астында тоту урыны урнашкан Россия Федерациясе субъектының сайлау комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

5) 27 статьяның 4 өлешендәге ахыргы җөмләсендә «Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе» сүзләрен «территориясендә сак астында тоту урыны урнашкан Россия Федерациясе субъектының сайлау комиссиясе» сүзләренә алмаштырырга;

6) 31 статьяның 2 өлешендә «дәүләт яисә муниципаль вакытлы матбугат басмаларында бастырып чыгарылырга тиеш, шулай ук ул» сүзләрен төшереп калдырырга;

7) 61 статьяда:

а) түбәндәге эчтәлекле $3^1$ өлеш өстәргә:

«$3^1$. Бермандатлы (күпмандатлы) сайлау округлары һәм бердәм сайлау округы буенча үткәрелә торган Дәүләт Советы депутатларын, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутатларын сайлауларда әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән, тиешенчә региональ дәүләт яисә муниципаль телерадиотапшырулар оешмалары тарафыннан бирелә торган эфир вакытының гомуми күләменең икедән бере тигез өлешләрдә теркәлгән кандидатлар исемлекләрен күрсәткән сайлау берләшмәләре арасында бүленә. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән, тиешенчә региональ дәүләт яисә муниципаль телерадиотапшырулар оешмалары тарафыннан бирелә торган эфир вакытының гомуми күләменең калган өлеше тигез өлешләрдә бермандатлы (күпмандатлы) сайлау округлары буенча күрсәтелгән барлык теркәлгән кандидатлар арасында бүленә.»;

б) 6 өлештә «муниципаль телерадиотапшырулар оешмалары» сүзләреннән соң «тигез өлешләрдә» сүзләрен өстәргә;

8) 62 статьяда:

а) $1^1$ өлешкә түбәндәге эчтәлекле өченче җөмлә өстәргә:

«Дәүләт Советы депутатларын, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутатларын сайлауларны бер үк вакытта бердәм сайлау округы һәм бермандатлы (күпмандатлы) сайлау округлары буенча үткәргәндә региональ (республика) дәүләт вакытлы матбугат басмасы редакциясе яисә муниципаль вакытлы матбугат басмасы редакциясе тарафыннан бирелә торган матбугат мәйданының гомуми күләменнән яртысы – теркәлгән кандидатлар исемлекләрен күрсәткән сайлау берләшмәләренә сайлау алды агитациясе алып бару, калган яртысы бермандатлы (күпмандатлы) сайлау округлары буенча теркәлгән кандидатлар тарафыннан сайлау алды агитациясе алып бару өчен бирелә.»;

б) 3 өлешне түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3. Сайлау алды агитациясен алып бару өчен вакытлы матбугат басмасы редакциясе тарафыннан $1^1$ өлеш нигезендә бирелә торган түләүсез матбугат мәйданының гомуми күләме теркәлгән кандидатлар, теркәлгән кандидатлар исемлекләрен күрсәткән сайлау берләшмәләре арасында шушы күләмне әлеге вакытлы матбугат басмасында түләүсез матбугат мәйданы алуга хокукы булган теркәлгән кандидатлар, теркәлгән кандидатлар исемлекләрен күрсәткән сайлау берләшмәләре санына бүлү юлы белән бүленә.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Рәисе

**«Татарстан Республикасы Сайлау кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проектына аңлатма**

«Татарстан Республикасы Сайлау кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проекты (алга таба – закон проекты) Татарстан Республикасы Сайлау кодексы нормаларын Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарына һәм җирле үзидарә органнарына сайлаулар буенча сайлау кампанияләренә әзерлек кысаларында, шулай ук «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законга (алга таба – 67-ФЗ номерлы Федераль закон) туры китерү максатларында актуальләштерү максатларында әзерләнде.

Закон проекты белән чит ил гражданнарының, гражданлыгы булмаган затларның, чит ил оешмаларының, халыкара оешмаларның һәм халыкара иҗтимагый хәрәкәтләрнең, чит ил агентларының кандидатларны, кандидатлар исемлекләрен күрсәтүгә, теркәлгән кандидатларны сайлауга, сайлауларда билгеле бер нәтиҗәгә ирешүгә ярдәм йә комачау итә торган эшчәнлекне гамәлгә ашырырга, шулай ук башка рәвешләрдә сайлау кампанияләрендә катнашырга хокуксыз булуы турында норманы беркетү тәкъдим ителә.

Закон проекты белән Татарстан Республикасы Рәисе вазыйфасына кандидат итеп Россия Федерациясендә даими яшәүче, пассив сайлау хокукына ия булган, тавыш бирү көненә 30 яшькә җиткән Россия Федерациясе гражданы күрсәтелү мөмкинлеге турындагы нигезләмә төгәлләштерелә.

67-ФЗ номерлы Федераль закон нормаларын гамәлгә ашыру һәм бермандатлы сайлау округлары һәм бердәм сайлау округы буенча үткәрелә торган Татарстан Республикасы Дәүләт Советы депутатларын, муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутатларын сайлауларны үткәргәндә түләүсез эфир вакытын һәм түләүсез матбугат мәйданын бүлү шартларын җайга салу максатларында закон проекты белән түләүсез эфир вакытын һәм түләүсез матбугат мәйданын бүлү тәртибе билгеләнә (тиешенчә региональ дәүләт яисә муниципаль телерадиотапшырулар оешмалары тарафыннан бирелә торган эфир вакыты, матбугат мәйданы гомуми күләменең икедән бере тигез өлешләрдә – теркәлгән кандидатлар исемлекләрен күрсәткән сайлау берләшмәләре, калган өлеше теркәлгән кандидатлар арасында бүленә).

Закон проекты гражданнарның сайлау хокукларын гамәлгә ашыру гарантияләрен тәэмин итүгә юнәлдерелгән, шулай ук Татарстан Республикасында сайлау процессын хокукый җайга салуны камилләштерү эшен алга таба да алып баруга ярдәм итәчәк.

**«Татарстан Республикасы Сайлау кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итүгә бәйле рәвештә үз көчләрен югалтуы танылырга, туктатып торылырга, үзгәртелергә яисә кабул ителергә тиешле Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары**

**ИСЕМЛЕГЕ**

«Татарстан Республикасы Сайлау кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы законнарының һәм башка норматив хокукый актларының үз көчләрен югалтуын тануны, аларны туктатып торуны, үзгәртүне яисә башкаларын кабул итүне таләп итми.

**«Татарстан Республикасы Сайлау кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законы проектына финанс-икътисадый нигезләү**

«Татарстан Республикасы Сайлау кодексына үзгәрешләр кертү турында» Татарстан Республикасы законын кабул итү Татарстан Республикасы бюджетыннан өстәмә финанслауны таләп итми.